**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ул.Комарова, д.14,**
**с.Шешминская Крепость,**
**423104**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**Комаров урамы, 14 йорты,**
**Шешминка Крепосте авылы,**
**423104**

**тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru**

**№105** **24 август, 2018 ел**

**Татарстан**
**Республикасы**
**Чирмешән муниципаль**
**районы Шешминка авыл**
**җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 апрелендә кабул ителгән 93 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында
«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, 2013 елның 26 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июлендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы **карары:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында:

- I бүлектәге «Шешминка авыл җирлеге башлыгы өчен түләү»: - 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.Шешминка авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата түләү түләнә. Айлык акчалата түләү өлешендә күрсәтелгән затларның хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме авыл җирлеге башлыгы өчен елына 4,65 айлык акчалата бүләкне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш»;

-түбәндәге эчтәлек белән 4.1 пунктын тулыландырырга : «4.1.Авыл җирлеге башлыгына, ай саен акчалата бүләк һәм ел саен түләнә торган отпуск вакытында бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә, муниципаль хокукый актлар нигезендә премияләр дә өстәмә түләнә ала».

Совет Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Башлыгы урынбасары:

**С.Н.Гладкова**